РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

06.03.2020 № 377-п

Саба муниципаль районы Башкарма комитетының 2019 елның 5 декабрендәге 1666-п номерлы карары белән расланган авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә 2019 елда нәселле терлекчелеккә ярдәм итүгә тотылган чыгымнарны каплауга субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

РФ Хөкүмәтенең “Юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләренә субсидияләрдән тыш), шәхси эшмәкәрләргә, шулай ук физик затларга - эшләр, хезмәт күрсәтүләр, товарлар җитештерүчеләргә субсидияләр бирүне җайга салучы норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләргә үзгәрешләр кертү турында” 2019 елның 12 сентябрендәге 1187 номерлы карары кабул ителүгә бәйле рәвештә, Саба муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Саба муниципаль районы Башкарма комитетының “Авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә 2019 елда нәселле терлекчелеккә ярдәм итүгә тотылган чыгымнарны каплауга субсидияләр бирү тәртибен раслау турында” 2019 елның 5 декабрендәге 1666-п номерлы карары белән расланган авыл хуҗалыгы товар җитештерүчеләренә 2019 елда нәселле терлекчелеккә ярдәм итүгә тотылган чыгымнарны каплауга субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 2.6 пунктының дүртенче абзацында “банкротлык” сүзен “аларга карата банкротлык процедурасы кертелмәгән, субсидия алучының эшчәнлеге Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә туктатылмаган” сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарның гамәлдә булуын 2019 елның 5 декабреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә таратырга.

3. Әлеге карарны Интернет челтәрендә - Татарстан Республикасының Хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында бастырып чыгарырга.

Җитәкче М.Р. Ишниязов